**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3758**
**23.07.2019**

Массакүләм чара үткәргәндә Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында

Массакүләм чара үткәрелү уңаеннан, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юллар эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ санлы Федераль законның 30 маддәсе, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ санлы Законының 27 маддәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 нче карары, шәһәр Уставының 41 маддәсе 9 пунктының 24.1 пунктчасы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2019 елның 23 августында 17:00 сәгатьтән 22:30 сәгатькә кадәр ике юнәлештә дә Хәсән Туфан проспекты буенча Чулман проспектыннан Раскольников урамына кадәр автомобиль юлы участогында, Раскольников урамы буенча Рәис Беляев проспектыннан Хәсән Туфан проспектына кадәр автомобиль юлы участогында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә.

2. Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенә чара үткәрү чорында гражданнар иминлеген, җәмәгать тәртибен һәм юл хәрәкәтен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

3. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә массакүләм мәгълүмат чаралары аша, шулай ук әлеге карарны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтларында

урнаштыру юлы белән транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертү турында автомобиль юлларыннан файдаланучыларга хәбәр итүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин